КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 3 март г.Казань № 123

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 817 нче карары белән расланган Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәкләр җитештерүгә һәм сатуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 817 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 26 декабрь, 1206 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәкләр җитештерүгә һәм сатуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «беренче сортлы арыш һәм бодай онынннан катнаштырып изелгән икмәкләр» сүзләрен «беренче һәм (яисә) икенче сортлы арыш һәм бодай онынннан катнаштырып изелгән икмәкләр» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агымдагы елда ай саен кимендә 2 тонна социаль икмәкләр җитештерү һәм үз сәүдә челтәре аша юридик затларга, һәм (яки) индивидуаль эшкуарларга, һәм (яки)

ваклап сатып алучыларга сату.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Хисап ае өчен субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \sum_{i=1}^{n} W_o + \sum_{i=1}^{y} W_r,$$

монда:

i – социаль икмәк төре;

n – җитештерелгән һәм юридик затларга һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларга сатылган социаль икмәкләр төрләре саны;

y – җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкләр төрләре саны;

$W_o$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга сатылган социаль икмәкләрнең i төре буенча субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_o = V_{io} \times W_{1\,кг\,io},$$

монда:

$V_{io}$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга сатылган социаль икмәкнең i төре күләме (кг);

$W_{1\,кг\,io}$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга сатылган социаль икмәкнең 1 кг i төре өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{1\,кг\,io} = (C_i - Ц_{cio}), \text{ әмма 1 килограмм өчен иң күбе 6,0 сум},$$

монда:

$C_i$ – хисап ае өчен социаль икмәкнең 1 кг i төрен җитештерүнең факттагы үзкыйммәте, сум;

$Ц_{cio}$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга сатылган социаль икмәкнең 1 кг i төрен сатуның уртача кыйммәте (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ц_{cio} = \frac{\sum_{i=1}^{n} (V_{io} \times Ц_{io})}{\sum_{i=1}^{n} V_{io}},$$

монда:

$Ц_{io}$ – хисап ае өчен юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга социаль икмәкнең i төрен сату бәясе (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда);

$W_r$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәрләре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкләрнең i төре буенча субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_r = V_{ir} \times W_{1\ кг\ ir},$$

монда:

$V_{ir}$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкнең i төре күләме (кг);

$W_{1\ кг\ ir}$ – хисап ае өчен җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкнең 1 килограмм i төре өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{1\ кг\ ir} = (C_{ir} - Ц_{cir}), \text{ әмма 1 килограмм өчен иң күбе 6,0 сум},$$

монда:

$C_{ir}$ – сәүдә челтәре чыгымнарын исәпкә алып, хисап ае өчен җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкнең 1 килограмм i төренең факттагы үзкыйммәте (сумда);

$Ц_{cir}$ – хисап ае өчен, сәүдә өстәмә бәясен исәпкә алып, җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган социаль икмәкнең 1 килограмм i төрен сатуның уртача бәясе (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ц_{cir} = \frac{S_{ir}}{V_{ir}},$$

монда $S_{ir}$ – хисап ае өчен, сәүдә өстәмә бәясен исәпкә алып, үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатылган үз җитештерүендәге социаль икмәкнең i төрен сатудан керем (сумда).»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә заявка формалаштыра һәм тапшыра, түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасына күчереп кертә:

Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча хисап чоры өчен субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләменең исәп-хисаплары турында белешмә кәгазьләре;

ирекле формада бухгалтерлык исәбе документлары нигезендә төзелгән хисап ае өчен социаль икмәкнең һәр төрен җитештерү үзкыйммәте турында белешмә кәгазьләре;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, сатудан алынган гомуми керемне күрсәтеп, үз сәүдә челтәре аша ваклап сатып алучыларга сатыла торган социаль икмәкнең 1 килограмм һәр төрен сатуның факттагы үзкыйммәте һәм уртача

бәясе турында белешмә кәгазе;

он һәм (яисә) бодай сатып алуга шартнамәләр, хисап чоры өчен он һәм (яисә) бодай өчен түләү фактын раслый торган накладной һәм түләү документлары реестры;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча икмәк белән тәэмин итүгә товар накладнойлары нигезендә төзелгән, хисап ае өчен 1 килограмм социаль икмәкнең факттагы һәм уртача бәясе турында мәгълүмат (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) бирелгән, хисап ае өчен җитештерелгән һәм сатылган социаль икмәкләр күләмнәре турында реестр;

ирекле формада икмәк белән тәэмин итүгә товар накладнойлары нигезендә җитештерелгән һәм үз сәүдә челтәре аша сатылган социаль икмәкләр күләмнәре турында төзелгән реестр;

чыгарыла торган социаль икмәкләрнең рецептуралары;

ирекле формада социаль икмәкләр җитештерүгә он тоту турында белешмә кәгазьләре;

килешүләр өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формада каралган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән күрсәткече турында хисап.

Документлар сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән расланган булырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин